| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.06.2017 Казан ш. № 147

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаш-тыручы табигый монополияләр субъ-ектлары, электр энергиясен күмәр-тәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче опера-торлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм көчен югалтуларын тану турында» 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләре үтәлүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»

2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә,
б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын расларга.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 2017 елның
19 июнендәге № 147 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламенты

# 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ АТАЛЫШЫ

1.1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт функциясен үтәгәндә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының административ процедураларының, административ гамәлләренең вакытларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең аталышы: «Газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар

тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) (алга таба, тиешенчә – дәүләт функциясе, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)) гамәлгә ашыру».

1.2. Дәүләт функциясен үтәүче булып Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тора.

Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре дәүләт функциясен турыдан-туры үтәүчеләр булып торалар, алар турындагы нигезләмәләрдә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру каралган.

Дәүләт функциясе турыдан-туры Дәүләт комитеты рәисенең, Дәүләт комитеты рәисе урынбасарының боерыгы нигезендә тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан үтәлә.

Дәүләт функциясен үтәгәндә Дәүләт комитеты Татарстан Республикасының прокуратура органнары (алга таба – прокуратура органнары), экспертлар, экспертлык оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, үзеннән-үзе җайга салынучы оешмалар, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән багланышларда тора.

Тиешле мәгълүматларны «Бердәм тикшерүләр реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – бердәм тикшерүләр реестры) кертү Дәүләт комитетының вәкаләт бирелгән вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ ҮТӘЛҮНЕ ҖАЙГА САЛА ТОРГАН НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт функциясе түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2002, № 1, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3426 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 89-ФЗ Федераль закон), (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 1998, № 26, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 05.04.1999, № 14, 1667 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2003, № 13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2005, № 1, 36 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон)(Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 190-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4159 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – № 416-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 50, 7358 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сатучы субъектлар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын раслау турында» 2004 елның 21 гыйнварындагы 24 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 21 гыйнварындагы № 24 карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2004, № 4, 282 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнарының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә табигый монополияләр субъектларының эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда катнашулары хакында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 15.12.2008, № 50, 5971 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерү үткәрүләрнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүен тикшереп тору

кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 28 сентябрендәге 764 номерлы карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 40, 5090, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торбаүткәргечләр буенча газ транспортлау хезмәтләрен күрсәтүче табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары турында» 2010 елның 29 октябрендәге 872 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 29 октябрендәге № 872 карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 45, 5855 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары турында» 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы № 6 карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2013, № 3, 205 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының көчләрен югалтуын тану турында» 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2013, № 27, 3602 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары һәм җайга салучы органнар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары турында» 2013 елның 5 июлендәге 570 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 июлендәге № 570 карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2013, № 28, 3835 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 415 карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларын раслау турында» 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2016, № 26, 4068 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар тапшыру һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге № 166 карары)

(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, бастырып чыгару номеры: 0001201702140002);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 724-р боерыгы) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Федераль тарифлар хезмәтенең «Табигый монополияләрнең субъектлары булган электр энергиясе һәм куәте базарлары субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу рәвешләрен раслау турында» 2014 елның 24 октябрендәге 1831-э номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 15 гыйнвар, бастырып чыгару номеры: 0001201501150004);

Федераль тарифлар хезмәтенең «Торбаүткәргечләр буенча газ транспортлаштыру хезмәтләрен күрсәтүче табигый монополияләр субъектлары тарафыннан мәгълүмат ачу рәвешләрен, вакытларын һәм ешлыгын, шулай ук күрсәтелгән рәвешләрне тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 31 гыйнварындагы 36-э номерлы боерыгы (Российская газета, 2011, 6 апрель);

Федераль тарифлар хезмәтенең «Кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм тарифларны җайга салучы органнар тарафыннан ачылырга тиешле мәгълүматны тапшыру рәвешләрен, шулай ук Мондый рәвешләрне тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 15 маендагы 129 номерлы боерыгы (Российская газета, 2013, 14 июль);

Федераль тарифлар хезмәтенең «Интернет» челтәрендә бастырып чыгару һәм Россия Федерациясе субъектының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге башкарма хакимият органнарының (су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифлар раслау буенча вәкаләтләр Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган очракта, – җирлекнең яисә шәһәр округының җирле үзидарә органнарының) мәгълүматны ачканда аны «Интернет» челтәрендә бастырып чыгару юлы белән җайга салынучы оешмалар белән хезмәттәшлек итүе юлы белән Мәгълүмат ачу регламентын раслау турында» 2014 елның 16 декабрендәге 2244-э номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 6 апрель, бастырып чыгару номеры: 0001201504060024);

Федераль тарифлар хезмәтенең «Мәгълүмат ачу стандартлары үтәлүне системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау турында хисап һәм электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылы белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләргә (тарифларга) кертелгән инвестиция

ресурсларыннан файдалануны системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау турында хисап рәвешләрен раслау турында» 2014 елның 20 февралендәге 201-э номерлы боерыгы (алга таба – № 201-э боерык) (Российская газета, 2014, 4 июнь);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2011, № 10, 1214 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләре үтәлүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 7, 0194 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 04.08.2010, № 29, 1195 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче коммуналь комплекс оешмалары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны ачу рәвешләрен раслау турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 358 номерлы боерыгы («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 19-20, 0682 ст.).

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ОБЪЕКТЛАРЫ

1.4. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты булып җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы түбәндәге юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның (алга таба – юридик затлар, шәхси эшкуарлар) эшчәнлеге тора:

– Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыру өлкәсендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектларының;

– электр энергиясен күмәртәләп сату базары субъектларының (Россия Федерациясе субъектының җайга салучы органы вәкаләтенә караган өлешендә);

– электр энергиясен ваклап сату базары субъектларының;

– җылы белән тәэмин итүче оешмаларның;

– җылылык челтәрләре оешмаларының;

– каты көнкүреш калдыкларын утильләштерүне, йогышсызландыруны һәм күмүне гамәлгә ашыручы коммуналь комплекс оешмаларының;

– каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторларының;

– каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторларның;

– кайнар су белән тәэмин итүче оешмаларның;

– салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмаарның.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕНЕҢ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕНЕҢ) ПРЕДМЕТЫ

1.5. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы булып юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру процессында мәгълүмат ачу стандартларын үтәү өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә законнардагы зарури таләпләрнең (алга таба – зарури таләпләр) үтәлүе тора, ә атап әйткәндә:

а) мәгълүматны ачу факты;

б) мәгълүматны бастырып чыгару чыганагы;

в) мәгълүмат ачуның вакытлары һәм ешлыгы;

г) мәгълүматны ачуның тулы булуы;

д) Дәүләт комитетына мәгълүматны бастырып чыгару чыганаклары турында хәбәр итү тәртибе;

е) мәгълүмат тапшыруның билгеләнгән тәртиптә расланган формалары һәм мондый формаларны тутыру кагыйдәләрен үтәү;

ж) ачылган мәгълүматның дөреслеге;

з) юридик затларның, шәхси эшкуарларның товарларыннан һәм хезмәтләреннән файдаланучыларның язмача гарызнамәләре буенча мәгълүмат ачу, шул исәптән гарызнамәләрне теркәү, аларны карап тикшерүне вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкару, шулай ук карап тикшерү нәтиҗәләре хакында хәбәр итү тәртибе.

1.6. Бу Регламентта кулланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр № 294-ФЗ Федераль законда, бүтән федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРГАНДА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.7 Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәлилле язмача гарызнамәләр нигезендә юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан тикшерүне үткәрү барышында кирәкле булган мәгълүматны һәм документларны соратырга һәм алырга;

2) түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;

3) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә бозуларның ачыкланган фактлары буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чараларны күрергә;

4) аңа карата тикшерү үткәрелә торган юридик зат, шәхси эшкуар белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, экспертлык оешмаларын тикшерүне үткәрүгә җәлеп итәргә.

1.8. Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлары түбәндәгеләрне бурычлы:

1) зарури таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, аларга карата төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) үткәрелә торган юридик затларның, шәхси эшкуарларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

3) тикшерүне Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) аның билгеләнүенә бәйле рәвештә аны үткәрү турындагы боерыгы нигезендә үткәрергә;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына, урынга чыгып тикшерүне бары тик хезмәт таныкларын, Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) боерыгы күчермәсен һәм, № 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясының 5 өлешендә каралган очракта, тикшерүне үткәрүнең килештерелүе турында документ күчермәсен күрсәткәндә генә үткәрергә;

5)юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүне үткәргәндә

катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәскә;

6) тикшерүне үткәргәндә катнашучы юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагыла торган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) юридик зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) юридик зат җитәкчесен, бүтән вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән таныштырырга;

9) ачыкланган бозу фактлары буенча күреләчәк чараларны билгеләгәндә күрсәтелгән чараларның бозуларның авырлыгына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез рәвештә чикләнүгә юл куймаска;

10) юридик зат, шәхси эшкуар шикаять иткәндә үзенең гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

11) тикшерүне үткәрүнең № 294-ФЗ Федераль законда билгеләнгән вакытларын сакларга;

12) юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан Россия Федерациясе законнарында аларны тапшыру каралмаган документларны һәм бүтән белешмәләрне таләп итмәскә;

13) урынга чыгып тикшерү үткәрә башлар алдыннан юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының яисә вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның соравы буенча аларны шушы Регламент нигезләмәләре белән таныштырырга;

14) юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу теркәргә;

15) 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәрге чорда планлы тикшерү үткәргәндә юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә № 294-ФЗ Федераль законның 26.1 статьясындагы нигезләмәләрнең эчтәлеген аңлатырга.

1.9. Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) әгәр дә шушы вазыйфаи затлар аның исеменнән эш кыла торган Дәүләт комитеты вәкаләтләренә карамаса, зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми

торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә (әлеге абзацтагы таләп 2017 елның 30 июненә кадәр гамәлдә);

3) СССР һәм РСФСР башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен, шулай ук аларны заруриа тәртиптә үтәү Россия Федерациясе законнарында каралмаган норматив документларның таләпләре үтәлешен тикшерергә (бу абзацтагы таләп 2017 елның 1 июленнән гамәлдә);

4) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган зарури таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

5) тикшерүне үткәргәндә юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмый торган очракта, планлы яки планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрүне гамәлгә ашырырга;

6) әгәр дә тикшерү объектлары булмаса яки тикшерү предметына карамаса, мондый документларны һәм мәгълүматларны тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның чын нөсхәләрен алырга;

7) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка төрле серне тәшкил итүче мәгълүматларны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

8) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән вакытларын арттырырга;

9) юридик затларга, шәхси эшкуарларга алар хисабыннан контроль чараларны үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнамәләр бирүне гамәлгә ашырырга;

10) юридик заттан, шәхси эшкуардан, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар карамагында булган рөхсәт итү документларын да кертеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелүче документларны һәм (яки) мәгълүматларны тапшыруларын таләп итәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшкуардан тикшерүне үткәрә башлаган датага кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруны таләп итәргә. Дәүләт комитеты тикшерү үткәрү турында боерык кабул ителгәч кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратырга хокуклы.

## АЛАРГА КАРАТА ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН ЮРИДИК ЗАТНЫҢ, ШӘХСИ ЭШКУАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.10. Юридик зат җитәкчесе, аның бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырылганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерүне үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) Дәүләт комитетыннан, Дәүләт комитетының вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына карый торган һәм № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә тапшырылырга тиешле мәгълүматларны алырга;

3) Дәүләт комитеты тарафыннан документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында булган оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән танышырга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны Дәүләт комитетына үз ихтыяры белән тапшырырга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән үзенең танышуы, алар белән, шулай ук Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның аерым гамәлләре белән ризалашуы яки ризалашмавы турында күрсәтергә;

6) тикшерүне үткәргәндә Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләрен (гамәл кылмауларын) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять кылырга;

7) Россия Федерациясе Президенты карамагында шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты карамагында шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашырга җәлеп итәргә;

8) билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитетына юридик затка, шәхси эшкуарга карата тикшерүне планлы тикшерүләрнең еллык планыннан төшереп калдыру турында гариза бирергә, әгәр дә тикшерүнең планлы тикшерүләрне үткәрүнең еллык планына кертелүе № 294-ФЗ Федераль законның 26.1 статьясындагы нигезләмәләрне бозып гамәлгә ашырылган дип уйласалар.

1.11. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар контроль (күзәтчелек) буенча чараларны гамәлгә ашырганда Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хокуксыз дип танылган гамәлләре (гамәл кылмавы) нәтиҗәсендә китерелгән зыянны түләттерү хокукына ия.

1.12. Юридик зат җитәкчесе, аның бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле аларга карата төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырылганда түбәндәгеләрне бурычлы:

1) Дәүләт комитетының вәкаләт бирелгән вазыйфаи затыннан дәлилле гарызнамә алынган көннән соң ун эш көне эчендә Дәүләт комитеты адресына гарызнамәдә күрсәтелгән документларны җибәрергә (документар тикшерү үткәрелгәндә);

2) урынга чыгып тикшерү үткәрелгәндә Дәүләт комитетындагы вәкаләт бирелгән, урынга чыгып тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларга, әгәр дә урынга чыгып тикшерү алдыннан документар тикшерү үткәрелмәгән булса, тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле булган документлар белән танышу мөмкинлеген тудырырга, шулай ук Дәүләт комитетындагы вәкаләт бирелгән, урынга чыгып тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларга һәм тикшерүдә катнашучы экспертларга, экспертлык оешмалары вәкилләренә юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда кулланыла торган территориягә, биналарга, төзелмәләргә, корылмаларга, бүлмәләргә, юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан кулланыла торган җайланмага, шуңа охшаш объектларга үтеп керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

3) катнашырга яисә зарури таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы булган, вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ГАМӘЛГӘ АШЫРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ

1.13. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда зарури таләпләрнең үтәлүен системалы рәвештә күзәтү, зарури таләпләрне үтәү торышын анализлау һәм фаразлау (алга таба – системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау) юлы белән гамәлгә ашырыла торган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау турында хисап (системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау турында хисап рәвеше Россия Федераль тарифлар хезмәтенең 20.02.2014 № 201-э боерыгы белән расланган);

бозулар ачыкланганда:

2) зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын туктату (юкка чыгару) турында күрсәтмә, аларны бетерү вакытларын күрсәтеп (алга таба – күрсәтмә) (шушы Регламентка 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча);

3) административ хокук бозу турында беркетмә (шушы Регламентка 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча);

4) административ хокук бозу эше буенча административ җәза билгеләү турында карар (шушы Регламентка 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча)

яисә административ хокук бозу эше буенча эшне туктату турында карар (шушы Регламентка 6 нчы кушымтада бирелгән форма буенча).

1.14. Тикшерүләр аша гамәлгә ашырыла торган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүен тикшерү акты (алга таба – тикшерү акты) (тикшерү үткәрү турында актның үрнәк рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган);

2) № 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

3) юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, урынга чыгып үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында теркәү (тикшерүләрне исәпкә алу журналының үрнәк рәвеше № 141 боерык белән расланган);

бозулар ачыкланганда:

4) зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын туктату (юкка чыгару) турында күрсәтмә, аларны бетерү вакытларын күрсәтеп (алга таба – күрсәтмә) (шушы Регламентка 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча);

5) административ хокук бозу турында беркетмә (шушы Регламентка 4 нче кушымтада бирелгән форма буенча);

6) административ хокук бозу эше буенча административ җәза билгеләү турында карар (шушы Регламентка 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча) яисә административ хокук бозу эше буенча эшне туктату турында карар (шушы Регламентка 6 нчы кушымтада бирелгән форма буенча).

Әгәр дә дәүләт функциясен үтәү өчен Дәүләт комитетына гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән мәгълүматлар нигез булып хезмәт итсә, дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә № 59-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ ҖИТКЕРҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Дәүләт комитетының урнашу урыны: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., К.Маркс ур., 66 й.

2.2. Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча документларны һәм мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен Дәүләт комитетының почта адресы: 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., К.Маркс ур., 66 й.

Электрон почта адресы: kt@tatar.ru;

Белешмә телефоны: (843)2218218.

2.3. Дәүләт комитетының эш графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр.

Төшке аш: 13.00 сәгатьтән 13.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

2.4. Дәүләт комитетының урнашкан урыны, телефоннары һәм эш графигы, почта һәм электрон адреслары турында мәгълүматлар Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге kt.tatarstan.ru рәсми сайтында (алга таба, тиешенчә, – Дәүләт комитетының рәсми сайты, «Интернет» челтәре) һәм Дәүләт комитеты фойесында урнаштырылган мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан бирелә:

– шәхси кабул итү кысаларында турыдан-туры;

– язмача рәвештә (шушы Регламентның 2.2 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча почта аша мөрәҗәгать иткәндә);

– электрон почта ярдәмендә (шушы Регламентның 2.2 пунктында күрсәтелгән электрон адрес буенча мөрәҗәгать иткәндә).

Телдән җиткерелгән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгать иткәннән соң кичекмәстән бирелә, язмача мөрәҗәгатькә һәм (яки) электрон почта аша килгән мөрәҗәгатькә җавап, тиешенчә, күрсәтелгән почта адресына яисә электрон адреска әлеге мөрәҗәгатьне Дәүләт комитетында теркәгән көннән соң календарь көннәрендә исәпләнә торган утыз көнлек чорда җибәрелә.

Кызыксынган затларга мәгълүмат бирүнең төп таләпләре: бирелгән мәгълүматның дөреслеге, мәгълүматны бәян итүдә төгәллек, мәгълүмат җиткерүнең тулы дәрәҗәдә булуы, мәгълүматны алуның уңайлы һәм үтемле булуы, мәгълүматны бирүнең оператив рәвештә башкарылуы.

2.5. Дәүләт комитетының рәсми сайтында – http://kt.tatarstan.ru/, мәгълүмат стендларында дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

1) урнашу урыны, элемтә телефоннары, «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтлар, электрон почта адреслары турындагы белешмәләр;

2) Россия Федерациясе законнарының һәм Татарстан Республикасы законнарының дәүләт функциясен үтәү тәртибенә кагыла торган төп нигезләмәләре турындагы мәгълүмат;

3) кушымталары белән бергә шушы Административ регламент тексты;

4) дәүләт функциясен үтәү баршы турында мәгълүмат;

5) юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләрне үткәрүләрнең еллык планы (алга таба – еллык План);

6) тикшерүне үткәргәндә Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын бозуга китергән гамәлләрен (гамәл кылмавын) шикаять кылу тәртибе.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕ (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ) БУЕНЧА ЧАРАЛАРНЫ ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРДАН ТҮЛӘҮ АЛУНЫҢ ЯРАМАГАНЛЫГЫ

2.6. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча чаралар үткәргән өчен юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан түләү алынмый, шул исәптән тикшерүләрне үткәрү өчен җәлеп ителгән очракта, экспертларның һәм экспертлык оешмаларының хезмәтләре өчен дә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ ВАКЫТЫ

2.7. Системалы рәвештә күзәтүнең һәм анализлауның вакытлары һәм ешлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан җайга салынучы эшчәнлек өлкәләрендә расланган мәгълүмат ачу стандартларында билгеләнгән мәгълүмат ачу вакытлары һәм ешлыгы нигезендә билгеләнә.

2.8. Планлы тикшерүне (документар, урынга чыгып) һәм планнан тыш тикшерүне (документар, урынга чыгып) үткәрү вакыты 20 эш көненнән артык була алмый.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, Дәүләт комитетының урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре нигезендә, урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрү вакыты Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк булган чорга түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – илле сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

Кече эшкуарлык субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерүне үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу зарурлыгы килеп чыккан очракта Дәүләт комитетының рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытка, ләкин иң күбе ун эш көненнән артмаган чорга туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору чоры гамәлдә булганда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бүлмәләрендә, бүтән объектларында Дәүләт комитетының күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатып торыла.

2.9. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр елына бер мәртәбәдән ешрак булмаган күләмдә үткәрелә.

## ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮ, СИСТЕМАЛЫ РӘВЕШТӘ КҮЗӘТҮ ҺӘМ АНАЛИЗЛАУ ӨЧЕН НИГЕЗЛӘР

2.10. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

– юридик затның, шәхси эшкуарның Дәүләт комитеты адресына җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен тарифлар билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе;

– Дәүләт комитетына массакүләм мәгълүмат чараларында, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә ачылырга тиешле мәгълүматның урнаштырылуы хакында хәбәр итү, – Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыру өлкәсендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары өчен;

– законнар нигезендә ачыла торган мәгълүматны урнаштыру (бастырып чыгару) вакытлары җитү, – Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыру өлкәсендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен.

2.11. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) Дәүләт комитеты тарафыннан расланган, № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә прокуратура органнары белән килештерелгән еллык План нигезендә кабул ителгән боерыгы нигезендә үткәрелә.

2.12. 2018 елның 31 декабренә кадәр «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы нигезләмәләре нигезендә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр үткәрелми. Әлеге абзацта күрсәтелгән затларга карата элек РФ КоАП нигезендә билгеләнгән җитди хокук бозган өчен административ җәза билгеләү турында яисә квалификациясеннән мәхрүм итү рәвешендә административ җәза билгеләү турында законлы көченә кергән карар чыгарылган булса һәм нәтиҗәсе мондый карарларны чыгару өчен сәбәпче булган тикшерүне үткәрүне тәмамлау датасыннан соң өч елдан азрак вакыт

узган булса, Дәүләт комитеты, планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын формалаштырганда, шушы Регламентның 2.13 пунктында каралган нигезләр буенча мондый затларга карата планлы тикшерүләр үткәрүне еллык планга кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

2.13. Түбәндәге вакыйга көненнән соң бер ел узып китсә, юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләрне еллык Планга кертү өчен нигез булып тора:

1) юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерү.

2.14. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш тикшерү үткәрү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

1) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу очрагын юкка чыгару турында Дәүләт комитеты тарафыннан элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан үтәлү вакыты узу;

2) Дәүләт комитетына юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрнең бозылуы турында гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары вазыйфаи затларыннан), җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар килү;

3) Дәүләт комитеты рәисенең Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган боерыгы.

Әгәр дә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ачыкланган зарури таләпләрне бозуны юкка чыгару турында күрсәтмәнең үтәлү чорының тәмамлануы планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез булып торса, мондый тикшерүнең предметы булып бары тик дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) органы һәм (яисә) муниципаль контроль органы тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.

2.15. Дәүләт комитетына мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге Регламентның 2.14 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмыйлар. Әгәр дә мөрәҗәгатьтә яисә гаризада бәян ителгән мәгълүмат, шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрүнең нигезе булып хезмәт итә алса, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты, мөрәҗәгатьнең яисә гаризаның авторына карата нигезле шикләре булганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча гакыллы чаралар күрергә бурычлы. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, аларның мөрәҗәгать

итүче тарафыннан бары тик бердәм идентефикацияләү һәм аутентификацияләү системасында мөрәҗәгать итүченең мәҗбүри авторлаштырылуын күздә тотучы мәгълүмати-коммуникация технологияләре чараларыннан файдаланып җибәрелгән булуы шарты белән генә, планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алалар.

2.16. Тикшерү башланганчыга кадәр аны оештыру өчен нигез булып хезмәт иткән мөрәҗәгатьнең яисә гаризаның аноним булуы ачыкланса, яисә мөрәҗәгатьтә яисә гаризада белә торып төгәл булмаган белешмәләрнең булуы билгеләнсә, Дәүләт комитетының рәисе, рәисе урынбасары карары нигезендә планнан тыш тикшерү туктатыла.

## ТӨБӘК ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН (КҮЗӘТЧЕЛЕГЕН) ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.18. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), вазыйфаи регламентларында тиешле эшчәнлек өлкәләрендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүләре каралган, Дәүләт комитетының түбәндәге структур бүлекчәләрендәге вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Коммуналь өлкә оешмаларын җайга салу идарәсенең коммуналь өлкә оешмаларын мониторинглау һәм күзәтү бүлегеннән:

түбәндәгеләргә карата:

а) кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне, су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар;

б) җылы белән тәэмин итүче оешмалар (электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару тәртибендә җылылык энергиясен җитештерүне гамәлгә ашыручы оешмалардан тыш);

в) җылылык челтәрләре оешмалары;

г) каты көнкүреш калдыкларын утильләштерүне, йогышсызландыруны һәм күмүне гамәлгә ашыручы коммуналь комплекс оешмалары;

д) каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары;

е) каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар;

түбәндәге очракларга карата:

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «а»-»е», «з» пунктчаларына (салкын су белән тәэмин итүнең, кайнар су белән тәэмин итүнең, су бүлүнең үзәкләштерелгән системаларына тоташтыру өчен расланган тарифлар турында, җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен расланган түләү турында, салкын су белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең, су бүлүнең) үзәкләштерелгән системасына тоташтыруның техник мөмкинлеге булу (булмавы) турында, шулай ук салкын су белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең, су бүлүнең) үзәкләштерелгән системасына тоташтыру турында заявкаларны теркәү һәм тормышка ашыру барышы турында, җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруның (технологик ялгауның) техник мөмкинлеге булу (булмавы) турында, шулай ук

җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен заявкаларны теркәү һәм тормышка ашыру барышы турында мәгълүматлар ачылуны тикшереп тору очрагыннан кала);

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «ж» пунктчасына, түбәндәгеләр буенча мәгълүмат ачуның дөреслеген тикшереп тору өлешендә: расланган тарифлар турында (эчә торган суга (эчә торган су белән тәэмин итү), техник суга, суны транспортлауга, су китерүгә, су бүлүгә, агынты суларны транспортлауга, кайнар суга (кайнар су белән тәэмин итү), кайнар суны транспортлауга, җылы белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче бүтән оешмаларга җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып җиткерелә торган кайнар суга, җылылык энергиясенә (куәтенә), җылы белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче бүтән оешмаларга бирелә торган җылыйөрткечкә, җылылык энергиясен, җылыйөрткечне тапшыру хезмәтләренә, җылылык энергиясе кулланылмаганда резервтагы җылылык куәтен саклау хезмәтләренә расланган түләү турында), ә атап әйткәндә: тарифларны раслау турында карар кабул иткән органның аталышы турында, мондый карарның реквизитлары (датасы һәм номер) турында, билгеләнгән тарифның күләме турында, тарифның гамәлдә булу чоры турында, карарны рәсми рәвештә бастырып чыгарган чыганак турында мәгълүматның);

2) катнаш эшләп чыгарудагы җылылык энергиясе тарифларын җайга салу бүлегеннән:

түбәндәгеләргә карата:

а) электр энергиясен һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару тәртибендә җылылык энергиясен (җылыйөрткеч) җитештерүне (китертүне) гамәлгә ашыручы җылы белән тәэмин итүче оешмаларга;

б) Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектларына;

түбәндәге очракларга карата:

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «а»-»е», «з» пунктчаларына (җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен расланган түләү турында, җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруның (технологик ялгауның) техник мөмкинлеге булу (булмавы) турында, шулай ук җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) заявкалар теркәү һәм тормышка ашыру барышы турында мәгълүмат ачылуны тикшереп торудан тыш);

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «ж» пунктчасына, – расланган тарифлар турында ачылган мәгълүматларның дөреслеген тикшереп тору өлешендә, ә атап әйткәндә: тарифларны раслау турында карар кабул иткән органның аталышы турында, мондый карарның реквизитлары (датасы һәм номер) турында, билгеләнгән тарифның күләме турында, тарифның гамәлдә булу

чоры турында, карарны рәсми рәвештә бастырып чыгарган чыганак турында мәгълүматның);

3) электр энергиясе тарифларын җайга салу бүлегеннән:

түбәндәгеләргә карата:

электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары субъектларына:

түбәндәге очракларга карата:

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «а»-»е», «з» пунктчаларына;

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «ж» пунктчасына (билгеләнгән тарифларның күләме турында ачылган мәгълүматларның дөреслеген тикшереп тору өлешендә);

4) технологик ялгау өчен түләүне җайга салу һәм тикшереп тору бүлегеннән:

түбәндәгеләргә карата:

а) былы белән тәэмин итүче оешмаларга;

б) җылылык челтәрләре оешмаларына;

в) кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга;

г) салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмаларга;

түбәндәге очракларга карата:

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «а»-»е», «з» пунктчаларына (салкын су белән тәэмин итүнең, кайнар су белән тәэмин итүнең, су бүлүнең үзәкләштерелгән системаларына тоташтыру өчен расланган тарифлар турында, җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен расланган түләү турында, салкын су белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең, су бүлүнең) үзәкләштерелгән системасына тоташтыруның техник мөмкинлеге булу (булмавы) турында, шулай ук салкын су белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең, су бүлүнең) үзәкләштерелгән системасына тоташтыру турында заявкаларны теркәү һәм тормышка ашыру барышы турында, җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыруның (технологик ялгауның) техник мөмкинлеге булу (булмавы) турында, шулай ук җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен заявкаларны теркәү һәм тормышка ашыру барышы турында мәгълүматлар ачылуны тикшереп тору өлешендә);

шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «ж» пунктчасына, түбәндәгеләр хакында ачылган мәгълүматларның дөреслеген тикшереп тору өлешендә: салкын су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына, су бүлүнең үзәкләштерелгән системасына, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасына тоташтыру өчен расланган тарифлар турында, җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен расланган түләү турында, ә атап әйткәндә: тарифларны раслау турында карар кабул иткән органның аталышы турында, мондый карарның реквизитлары (датасы һәм номеры) турында, билгеләнгән тарифның күләме турында, тарифның гамәлдә булу чоры турында, карарны рәсми рәвештә бастырып чыгару чыганагы турында мәгълүматларның;

5) административ хокук бозула эшләрен кузгату һәм административ хокук бозуларга юл куйган затларны административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү өлешендә административ тәҗрибә бүлегеннән.

2.19. Тикшерүләр ярдәмендә гамәлгә ашырыла торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турыдан-туры Дәүләт комитетында рәис (рәис урынбасары) боерыгы белән тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.20. Дәүләт функциясен гамәлгә ашыруга аларга карата тикшерү үткәрелүче юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм тикшерелә торган затларның аффилир затлары булмаган экспертлар, экспертлык оешмалары җәлеп ителергә мөмкин.

## № 294-ФЗ ФЕДЕРАЛЬ ЗАКОННЫ БОЗГАН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРНЫҢ, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫ БУЛУЫ

2.21. 294-ФЗ номерлы Федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез рәвештә каршы төшүче, тикшерүләрне үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) билгеләнгән чорларда Дәүләт комитетының зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәсен үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

## ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ, АНДАГЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫ БУЛУЫ

2.22. Дәүләт комитеты, андагы вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә, тиешенчә, функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә үтәмәгән очракта, хокукка каршы килә торган гамәлләрне кылганда (гамәл кылмаганда), Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгән көннән соң ун көн эчендә Дәүләт комитеты язмача рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итәргә бурычлы.

# 3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА БЕЛДЕРЕЛӘ ТОРГАН ЗАРУРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Үтәлешен Дәүләт комитеты тикшереп тора торган, юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата белдерелә торган зарури таләпләрнең исемлеге, эшчәнлекнең зарури таләпләр куела торган төрләрен, зарури таләпләрне билгели торган таләпләрнең, норматив хокукый актларның төрләрен күрсәтеп, 1 нче таблицада китерелде.

1 нче таблица – Үтәлешен Дәүләт комитеты тикшереп тора торган, юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| № п/п | Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары | Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыру өлкәсендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектлары | Җайга салучы оешмалар тарафыннан түбәндәгеләрне үтәү:<br>- мәгълүмат ачу факты;<br>- мәгълүмат урнаштыру чыгынагы;<br>- мәгълүмат ачуның вакытлары һәм ешлыгы;<br>- мәгълүмат ачуның тулы дәрәҗәдә булуы;<br>- Дәүләт комитетына мәгълүматны бастырып чыгару чыганаклары турында хәбәр итү тәртибе;<br>- мәгълүмат тапшыруның билгеләнгән тәртиптә расланган формалары һәм мондый формаларны тутыру кагыйдәләрен үтәү;<br>- ачылган мәгълүматның | № 147-ФЗ Федераль законның 8 статьясының 5 өлеше, 8.1 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 29 октябрендәге № 872 карары;<br>Россия ФТХ 2011 елның 31 гыйнварындагы № 36-э боерыгы |
| 2 | электр энергиясен күмәртәләп сату базары субъектлары (Россия Федерациясе субъектының җайга салучы органы вәкаләтенә караган өлешендә) | | № 147-ФЗ Федераль законның 8 статьясының 5 өлеше, 8.1 статьясы;<br>№ 35-ФЗ Федераль законның 24 статьясының 3 өлеше;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 21 гыйнварындагы № 24 карары |
| 3 | электр энергиясен ваклап сату базары | | |

| №<br>п/п | Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары | Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | субъектлары | дөреслеге;<br>- юридик затларның, шәхси эшкуарларның товарларыннан һәм хезмәтләреннән файдаланучыларның язмача гарызнамәләре буенча мәгълүмат ачу, шул исәптән гарызнамәләрне теркәү, аларны карап тикшерүне вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкару, шулай ук карап тикшерү нәтиҗәләре хакында хәбәр итү тәртибе | |
| 3 | җылы белән тәэмин итүче оешмалар | | № 147-ФЗ Федераль законның 8 статьясының 5 өлеше, 8.1 статьясы;<br>№ 190-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 11 өлеше;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 июлендәге № 570 карары |
| 4 | җылылык челтәрләре оешмалары | | |
| 5 | каты көнкүреш калдыкларын утильләштерүне, йогышсызландыруны һәм күмүне гамәлгә ашыручы коммуналь комплекс оешмалары; | | 2004 елның 30 декабрендәге № 210-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 4-8 өлешләре, 17.1 статьясы |
| 6 | каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары | | № 89 Федераль законның 24.11 статьясының 2 өлеше, 24.12 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге № 564 карары |
| 7 | каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар | | |
| 8 | кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар | | № 147-ФЗ Федераль законның 8 статьясының 5 өлеше, 8.1 статьясы;<br>№ 416 Федераль законның 34 статьясы, 35 статьясы;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы № 6 карары;<br>Федераль тарифлар хезмәтенең 2013 елның 15 маендагы № 129 боерыгы |

3.2. Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләрнең бозылуын кисәтү, зарури таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында Дәүләт комитеты ел саен үзе тарафыннан расланучы бозуларны профилактикалау программасы нигезендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә зарури таләпләрнең бозылуын профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.

Дәүләт комитетында килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм

мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларда бәян ителгән зарури таләпләрне бозуларның әзерләнеп ятуы яисә бозылу билгеләре хакында мәгълүматлар булганда, әгәр дә юридик зат, шәхси эшкуар элек тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган булса, Дәүләт комитеты юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта шул кисәтүдә билгеләнгән чорда Дәүләт комитетына хәбәр итәргә тәкъдим итә.

Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар белдерүе һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү тәртибе Дәүләт комитеты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ЮРИДИК ЗАТ, ШӘХСИ ЭШКУАР ТАРАФЫННАН ТАПШЫРЫЛА ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив хокукый актлар 2 нче таблицада китерелде.

2 нче таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| №№ п/п | Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | Гражданинның, шәхси эшкуарның, юридик затның законлы вәкиленең, аларның вәкаләтле вәкилләренең шәхесен таныклаучы документлары | |
| 2 | Юридик затның, шәхси эшкуарның яисә гражданинның мәнфәгатьләрен белдерүче затның вәкаләтләрен раслаучы документлар | |
| 3 | Ирекле файдаланырга тиешле мәгълүматны бирү турында кулланучылардан юридик зат, шәхси эшкуар адресына килгән язмача гарызнамәләрнең теркәлүен раслый торган документлар | |
| 4 | Ирекле файдаланырга тиешле мәгълүматны бирү турында кулланучылардан юридик зат, шәхси эшкуар адресына килгән язмача гарызнамәләргә бирелгән җавапларның күчермәләре | |
| 5 | Мәгълүматны ачу турындагы законнарда билгеләнгән очракта һәм күләмнәрдә басма матбугатларда ачылырга тиешле | |

| №№ п/п | Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ | Документ рәвешен билгеле торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| | мәгълүмат басылып чыккан матбугат басмалары | |

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫҢ (ГАМӘЛЛӘРНЕҢ) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ҮТӘҮ ВАКЫТЛАРЫ, АЛАРНЫ ҮТӘҮ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘРНЕ) ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ ҮТӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮ КЫСАЛАРЫНДА ГАМӘЛГӘ АШЫРЫЛА ТОРГАН АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

5.1. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәге административ процедуралар ярдәмендә гамәлгә ашырыла:

а) системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау;

б) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы документар тикшерү үткәрү;

в) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү;

г) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

д) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү.

5.2. Дәүләт функциясен үтәүнең Блок-схемасы шушы Регламентка 1 нче, 7 нче кушымталарда китерелде.

5.3. Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору рөхсәт ителә.

### «СИСТЕМАЛЫ РӘВЕШТӘ КҮЗӘТҮ ҺӘМ АНАЛИЗЛАУ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.4. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрү нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

– юридик затның, шәхси эшкуарның Дәүләт комитеты адресына җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар

су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен тарифлар билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе;

– Дәүләт комитетына массакүләм мәгълүмат чараларында, электрон массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә ачылырга тиешле мәгълүматның урнаштырылуы хакында хәбәр итү, – Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыру өлкәсендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары өчен;

– законнар нигезендә ачыла торган мәгълүматны урнаштыру (бастырып чыгару) вакытлары җитү, – Татарстан Республикасы территориясеннән читтә урнашкан газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлаштыру өлкәсендә эшчәнлек башкаручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен.

5.5. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау шушы Регламентның 1.5 пунктындагы «а»-»е» пунктчаларына карата Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан шушы Регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән Дәүләт комитеты бүлекләренең вәкаләтләренә һәм компетенцияләренә туры китереп башкарыла. Һәр юридик зат, шәхси эшкуар буенча Дәүләт комитетындагы тиешле бүлекнең башлыгы (алга таба – бүлек башлыгы) тарафыннан ачылган мәгълүматны системалы рәвештә күзәтүгә һәм анализлауга җаваплы булган вазыйфаи зат (алга таба – җаваплы башкаручы) билгеләнә.

5.6. Системалы рәвештә күзәтүне һәм анализлауны үткәргәндә җаваплы башкаручы тарафыннан түбәндәге гамәлләр гамәлгә ашырыла:

– юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлеге формалаштырыла;
– документлар һәм материаллар җыела;
– докуметлар һәм материаллар эшкәртелә һәм анализлана;
– системалы рәвештә күзәтүне һәм анализлауны үткәрү турында хисап әзерләнә.

5.7. Системалы рәвештә күзәтелергә һәм анализланырга тиешле юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлекләре җаваплы башкаручылар тарафыннан Дәүләт комитетының шушы Регламентның 2.18 пунктында күрсәтелгән бүлекләре компетенцияләренә туры китереп формалаштырыла һәм Дәүләт комитеты рәисенең тиешле эшчәнлек өлкәсендә тикшереп торучы урынбасары тарафыннан раслана (шушы Регламентка 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча).

Үтәү вакыты: төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрү чорыннан алдагы елның 1 декабренә кадәр.

Гамәлнең нәтиҗәсе: системалы рәвештә күзәтелергә һәм анализланырга

тиеле юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлеге.

5.8. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына кагыла торган документларны һәм материалларны җыю рәсми матбугат басмаларындагы, юридик затларның, шәхси эшкуарларның сайтларындагы, Дәүләт комитетының рәсми сайтындагы (kt.tatarstan.ru) төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына кагыла торган мәгълүматларны күзәтү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Җаваплы башкаручы тарафыннан юридик затларның, шәхси эшкуарларның мәгълүматны «Интернет» челтәрендә урнаштыру, шулай ук аның рәсми матбугат басмаларында бастыру урыны турында җибәрелгән хәбәрләренең исәбе алып барыла.

Үтәү вакыты: мәгълүмат ачу стандартларында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен билгеләнгән мәгълүмат ачу чоры беткән көннән соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: «Интернет» челтәрендә һәм рәсми басма матбугатларда табылган, дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына карый торган мәгълүмат.

5.9. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру өчен кирәкле булган документларны һәм материалларны җыю нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы тарафыннан документларга һәм материалларга түбәндәгеләр предметына карата эшкәртү һәм анализлау эше башкарыла:

– ачылган мәгълүматның бастырып чыгарылган чыганагында булуы;

– юридик затның, шәхси эшкуарның мәгълүмат урнаштыруның мәгълүмат ачу стандартларында билгеләнгән вакытларын һәм ешлыгын үтәве;

– юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан ачылган мәгълүматлар исемлегенең мәгълүмат ачу стандарты нигезендә ачыларга тиешле мәгълүматлар исемлегенә туры килүе, шулай ук мәгълүмат ачу формасында юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан искәрмәләр белән расланмаган, буш юллар калуы;

– тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге һәм хәбәр итү чорларының мәгълүмат ачу стандартларында каралган чорларга туры килүе;

– ачылган мәгълүматның аны ачу буенча расланган формаларга туры килүе.

Үтәү вакыты: мәгълүматларны, документларны һәм материалларны эшкәртү һәм анализлау шушы Регламентның 5.8 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары таләпләренең үтәлүен бәяләү.

5.10. Мәгълүматларны, документларны һәм материалларны җыю, эшкәртү һәм анализлау буенча кирәкле гамәлләрне башкару йомгаклары буенча җаваплы башкаручы системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрелүе турында хисап формалаштыра (системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрелүе турында

хисап рәвеше Россия Федераль тарифлар хезмәтенең 20.04.2014 № 201-э боерыгы белән расланган).

Ирекле файдаланырга тиешле мәгълүматның «Интернет» челтәрендә тулы дәрәҗәдә ачылмавы ачыкланган очракта җаваплы башкаручы мәгълүмат ачу стандартларында каралган мәгълүматлар арасындагы мәгълүматны үз эченә алучы сайт битләреннән экран сурәтләрен (скриншотлар) ясый, аларны бастырып чыгара, номер суга һәм, бастырып чыгарылган вакытын һәм датасын күрсәтеп, үзенең имзасы белән беркетә.

Хисап, карап тикшерелгән материаллар, ә бозулар ачыкланган очракта – экран сурәтләре (скриншотлар) танышу өчен бүлек башлыгына тапшырыла, алга таба карап тикшерү өчен Дәүләт комитеты рәисенең Дәүләт комитетының тиешле эшчәнлек юнәлешен тикшереп торучы урынбасарына тапшырыла.

Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрелүе турында хисап Дәүләт комитеты архивына тапшырылганчыга кадәр системалы рәвештә күзәтүне һәм анализлауны гамәлгә ашыручы белгечләрнең бүлекләрендә саклана.

Мәгълүмат ачу стандартларын бозу очраклары ачыкланганда, Дәүләт комитеты:

1) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартлары бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмә бирә;

2) Дәүләт комитеты вәкаләтләренә туры китереп, административ хокук бозулар турында эшләр кузгата.

Җаваплы башкаручы:

– күрсәтмә проектын (шушы Регламентка 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча) әзерли һәм, системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау нәтиҗәләре турында хисап төзелгән датадан соң бер эш көненнән соңга калмыйча, аны килештерү өчен бүлек башлыгына, Дәүләт комитеты рәисенең тикшереп торучы урынбасарына һәм имзалау өчен Дәүләт комитеты рәисенә тапшыра.

– имза салынган датадан соң ике эш көне эчендә күрсәтмәне юридик затка, шәхси эшкуарга гомуми эш башкару тәртибендә (кулга тапшыру тамгасы белән заказлы хат итеп) җибәрә яисә юридик затның законлы вәкиленә, шәхси эшкуарга (вәкаләтле вәкиленә) имза куйдыртып, кулына тапшыра;

– системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау нәтиҗәләре турында хисап төзелгән датадан соң бер эш көненнән дә соң булмаган чорда хисап күчермәсен ачыкланган бозуларга юл куйган вазыйфаи затларны һәм юридик затларны административ җаваплылыкка тарту буенча алга таба эш оештыру өчен Дәүләт комитетының административ тәҗрибә бүлегенә тапшыра.

Үтәү вакыты: системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрелүе турында хисап шушы Регламентның 5.9 пунктында каралган процедура тәмамланган датадан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча әзерләнергә тиеш, ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында кисәтү системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрелүе турында хисап төзелгән датадан соң бер эш көненнән дә соңга

калмыйча әзерләнергә һәм имза салу өчен Дәүләт комитеты рәисенә юлланырга тиеш.

Гамәлнең нәтиҗәсе: системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрелүе турында хисап, ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә, юридик затка, шәхси эшкуарга күрсәтмәне бирү.

5.11. Кузгатылган административ хокук бозу эшен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:

шушы Регламентка 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча административ җәза билгеләү турында карар;

шушы Регламентка 6 нчы кушымтада бирелгән форма буенча административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турында карар.

Үтәү вакыты: административ хокук бозу турында беркетмә төзелгән мизгелдән башлап унбиш көн дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: административ хокук бозу эше буенча административ җәза билгеләү турында карар яисә административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турында карар.

5.12. Административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турындагы карарның күчермәсе яисә административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турындагы карарның күчермәсе бу карар аларга карата чыгарылган физик затка, яисә физик затның законлы вәкиленә, яисә юридик затның законлы вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла, яисә күрсәтелгән затларга кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә.

Үтәү вакыты: административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турында карар яисә административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турында карар чыгарылган көннән башлап өч көн эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка яисә шәхси эшкуарга тапшырылган яки җибәрелгән административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турындагы карарның күчермәсе яисә административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турындагы карарның күчермәсе.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРГА ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТЛАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.13. Юридик затның, шәхси эшкуарның еллык Планга кертелүе һәм юридик затка, шәхси эшкуарга карата планлы тикшерү үткәрү вакытларының килеп җитүе «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедура административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла:

– тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;
– тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;

– юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерүне үткәрү хакында хәбәр итү;

– тикшерүне үткәрү;

– тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү.

5.14. Еллык План нигезендә үз компетенцияләре кысаларында тикшерү үткәрүче Дәүләт комитеты бүлекләре башлыклары юридик затларга, шәхси эшкуарларга тикшерү үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затларның исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

5.15. Җаваплы башкаручы:

– юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы документар тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган форма буенча);

– боерык проектын имза кую өчен Дәүләт комитеты рәисенә (рәисе урынбасарына) юллый.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы документар тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык.

5.16. Дәүләт комитеты юридик затка, шәхси эшкуарга Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) планлы документар тикшерү үткәрү турындагы боерыгы күчермәсен кулга тапшыру турында почта аша җибәрелгән заказлы хат ярдәмендә һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм, әгәр дә мондый адрес, тиешенчә, бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси эшкуарлар реестрында булса яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Дәүләт комитетына тапшырылган булса, юридик затның, шәхси эшкуарның электрон адресына җибәрелгән электрон документ аша яки бүтән үтемле ысул (факсимиль элемтә, электрон почта, кулга тапшыру тамгасы белән кулга биреп) белән планлы документар тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итә.

Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары планлы документар тикшерүне үткәрер алдыннан юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә № 294-ФЗ Федераль законның 26.1 статьясындагы нигезләмәләренең эчтәлеген аңлаталар. Планлы документар тикшерүне үткәргәндә Дәүләт комитетының вазыйфаи затларына аларга карата планлы документар тикшерү үткәрелә торган юридик затның, шәхси эшкуарның шушы Регламентның 2.12 пунктында күрсәтелгән затларга каравын раслый торган документлар тапшырылган очракта һәм, шушы

Регламентның 2.12 пунктында каралган нигезләр булмаганда, планлы документар тикшерүне үткәрү туктатыла, бу хакта тиешле акт төзелә.

Юридик затка, шәхси эшкуарга – үзеннән-үзе җайга салынучы оешма әгъзасына карата тикшерү үткәрелгән очракта җаваплы башкаручы шулай ук, планлы документар тикшерүне үткәргәндә аннан вәкил катнашу яисә булу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үзеннән-үзе җайга салынучы оешмага хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан 3 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү.

5.17. Юридик зат, шәхси эшкуар, боерык күчермәсен алган мизгелдән башлап 10 эш көне эчендә, Дәүләт комитетына планлы документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә бурычлы.

Күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм, тиешенчә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр дә Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Дәүләт комитетына тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхәт ителми.

Дәүләт комитеты юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

5.18. Тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар Дәүләт комитеты карамагында булган документлардагы белешмәләр һәм юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылган документлардагы белешмәләр нигезендә:

– белешмәләрнең дөрес булуына карата бәяләү үткәрә;

– документлардагы белешмәләрнең юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге билгеләнгән зарури таләпләргә туры килү-килмәве предметына карата бәяләү үткәрә.

Әгәр дә документар тикшерү барышында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылган документларда хаталар булуы һәм (яисә) каршылыклар, яисә бу документларда булган мәгълүматларның Дәүләт комитетында булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы:

– юридик затка, шәхси эшкуарга, белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат белән һәм 10 эш көнендә язмача рәвештә аңлатмалар һәм кирәкле бүтән документларны тапшыруын таләп итеп, хат (дәлилле гарызнамә) әзерли;

– хатны (дәлилле гарызнамәне) имза салу өчен Дәүләт комитеты рәисенә (рәисе урынбасарына) җибәрә;

– имзаланганнан соң хатны (дәлилле гарызнамәне), Дәүләт комитеты рәисе боерыгының күчермәсен теркәп, юридик затның, шәхси эшкуарның адресына кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп яисә бүтән үтемле ысул белән (факимиль элемтә, электрон почта, кулга алу турында тамгасы белән кулга тапшырып) җибәрә.

Тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яисә) каршылыкларга карата Дәүләт комитетына аңлатмалар бирүче юридик зат, шәхси эшкуар Дәүләт комитетына өстәмә рәвештә элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган документларны да тапшырырга хокуклы.

Элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмалар һәм (яисә) документлар алынганнан соң, тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган, элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карап тикшерәләр һәм җаваплы зат тикшерү актын төзи.

Әгәр дә тапшырылган, элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карап тикшергәннән соң яисә аңлатмалар булмаганда Дәүләт комитеты зарури таләпләрнең бозылу билгеләрен ачыкласа, Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары урынга чыгып тикшерү үткәрергә хокуклы. Бу очракта җаваплы башкаручы урынга чыгып тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли. Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карарны Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) кабул итә. Шул ук вакытта документар тикшерүнең нәтиҗәсе урынга чыгып тикшерү рәвешендә дәүләт функциясен үтәгәндә административ процедураны башлау өчен нигез белән туры киләчәк. Урынга чыгып тикшерү үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү үткәрү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итү тыела.

Үтәү вакыты: шушы Регламентның 2.8 пунктындагы таләпләргә туры китерелгән тикшерү үткәрү вакытлары.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган, карап тикшерелгән документлар, шул исәптән аңлатмалар һәм документлар; зарурлык булганда планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

5.19. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат ике нөсхәдә тикшерү акты төзи (тикшерү үткәрү турындагы актның үрнәк рәвеше Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган), аларга тикшерүне үткәргән вазыйфаи затлар тарафыннан имза салына.

Юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүен тикшерү нәтиҗәсендә бозулар ачыкланган очракта җаваплы

башкаручы түбәндәге гамәлләрне гамәлгә ашыра:

– тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган тикшерү нәтиҗәләре нигезендә ачыкланган бозуларны тикшерү актында терки;

– үз компетенцияләренә кагыла торган өлештә бозуларны тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган күрсәтмәләрнең проектлары нигезендә, бетерү чорларын күрсәтеп, тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында Дәүләт комитетының җыелма күрсәтмәсе проектын (шушы Регламентка 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча) әзерли, аңа Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан кул куела. Дәүләт комитеты күрсәтмәсенең билгеләнгән вакытларда үтәлүен тикшереп тору, бүлек компетенциясе кысаларында, тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Документар тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү актын рәсмиләштергәндә җаваплы башкаручы, зарурлык булганда, шулай ук аңа түбәндәгеләрне дә терки:

үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре яисә бәяләмәләре;

зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган юридик затның вазыйфаи затларының (вәкилләренең), шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең аңлатмалары;

тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган бүтән документлар яисә аларның күчермәләре.

Административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда административ хокук бозу эшләре буенча беркетмәләр төзү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, Дәүләт комитеты вәкаләтләренә нигезләнеп, РФ КоАП 9.15, 19.8.1 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында эшләр кузгата.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә теген куя һәм аны Дәүләт комитетына билгеләнгән тәртиптә тапшырганчыга кадәр саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга яисә аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тарту турындагы имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерүнамә Дәүләт комитеты эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты

юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

– акты төзү һәм кушымталары берлектә тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр дә актны төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

– билгеләнгән очракларда тикшерү актын кулга тапшыру турында тамгасы белән заказлы хат итеп һәм (яисә) әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрү, – контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә;

– тикшерү актын формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә саклау: билгеләнгән тәртиптә аны Дәүләт комитеты архивына тапшырганчыга кадәр норматив актларда билгеләнгән чорлар дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: кушымталары белән бергә ике нөсхәдәге тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә тегеп куелган һәм билгеләнгән тәртиптә формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә саклана.

Аларга карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Дәүләт комитетына тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.20. Кузгатылган административ хокук бозу эшен карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәге карарларның берсе чыгарыла:

шушы Регламентка 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча административ җәза билгеләү турында карар;

шушы Регламентка 6 нчы кушымтада бирелгән форма буенча административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турында карар.

Үтәү вакыты: административ хокук бозу турында беркетмә төзелгән мизгелдән башлап унбиш көн дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: административ хокук бозу эше буенча административ җәза билгеләү турында карар яисә административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турында карар.

5.21. Административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турындагы карарның күчермәсе яисә административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турындагы карарның күчермәсе бу карар аларга карата чыгарылган физик затка, яисә физик затның законлы вәкиленә, яисә юридик затның законлы вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла, яисә күрсәтелгән затларга кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә.

Үтәү вакыты: административ хокук бозу эше буенча администиратив җәза билгеләү турында карар яисә административ хокук бозу эше буенча эш башкаруны туктату турында карар чыгарылган көннән башлап өч көн эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка яисә шәхси эшкуарга тапшырылган яки җибәрелгән административ хокук бозу турында эш буенча администиратив җәза билгеләү турындагы карарның күчермәсе яисә административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны туктату турындагы карарның күчермәсе.

5.22. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә тиешле мәгълүматны, планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру турында хезмәт язуын җибәрә.

Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 415 карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертә.

Үтәү вакыты: мәгълүматны Дәүләт сайтында урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча;

мәгълүматны бердәм тикшерүләр реестрына кертү – билгеләнгән вакытларга туры китереп.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерүне башкару нәтиҗәләре хакында Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган һәм бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән мәгълүмат.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАНЛЫ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.23. Тиешле юридик затның, шәхси эшкуарның еллык Планга кертелүе һәм юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрүнең вакытлары килеп җитү «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга

карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора, шулай ук документар тикшерү барышында түбәндәгеләрнең мөмкин булмавы да:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерүнамәдә һәм юридик затның, шәхси эшкуарның Дәүләт комитеты карамагында булган бүтән документларында бәян ителгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп белү;

2) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү» административ процедурасы шушы Регламентның 5.13 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.24. Тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгеләү, урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү турында боерык әзерләү, юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планлы тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү шушы Регламентның 5.14-5.16 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.25. Урынга чыгып тикшерү Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан хезмәт таныклыгын күрсәтүдән, юридик затның җитәкчесен яисә бүтән вазыйфаи затын, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) урынга чыгып тикшерүнең билгеләнүе турындагы карары һәм урынга чыгып тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре белән, шулай ук урынга чыгып тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль буенча чараларның төрләре һәм күләмнәре, урынга чыгып тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертларның составы, экспертлык оешмаларының вәкилләре, аны үткәрүнең вакытлары һәм шартлары белән зарури тәртиптә таныштырудан башлана.

Тикшерелергә тиешле затларның таләбе буенча Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары үзләренең вәкаләтләрен раслау максатларында Дәүләт комитеты турында, шулай ук экспертлар, экспертлык оешмалары турында мәгълүмат бирергә бурычлы.

Юридик затның җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының һәм вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның гозере буенча Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны контроль буенча чаралар үткәрүнең административ регламентлары һәм аларны юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда файдаланыла торган объектларда үткәрү тәртибе белән таныштырырга бурычлы.

Тикшерү барышында Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектларының товарларын һәм хезмәтләрен кулланучыларның язмача гарызнамәләре буенча шушы Регламентның 4 нче бүлегендә китерелгән, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тиешле эшчәнлек өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартында билгеләнгән зарури таләпләрнең үтәлүе турында нәтиҗәләр формалаштыру

өчен әһәмиятле булган документлар, шул исәптән язмача гарызнамәләрне теркәүгә, аларның үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә каралуына, шулай ук карау нәтиҗәләре турында хәбәр итүгә бәйле документлар тикшерелә.

Тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар контроль буенча түбәндәге чараларны үткәрәләр:

1) мәгълүмат ачу стандартларын бозуның алдагы тикшерүдә ачыкланган очракларын бетерүнең тулы дәрәҗәдә башкарылуын тикшерәләр;

2) тикшерелә торган оешманың эшчәнлеген сыйфатлый торган документларны һәм материалларны тикшерү предметын гыйбарәт итүче мәсьәләләр буенча карап тикшерәләр.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрү вакыты – шушы Регламентның 2.8 пунктындагы таләпләргә туры китереп.

Гамәлнең нәтиҗәсе: контроль буенча үткәрелгән чаралар.

5.26. Тикшерү нәтиҗәләрен формалаштыру, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү шушы Регламентның 5.19-5.21 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.27. Җаваплы башкаручы юридик затларның, шәхси эшкуарларның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планлы тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы белешмәләрне үз эченә алган язуны терки, шулай ук тикшерүне үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планлы тикшерү турында теркәлгән язу.

5.28. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы шушы Регламентның 5.22 пункты нигезендә тиешле мәгълүматларның Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылуын һәм тиешле мәгълүматларның бердәм тикшерүләр реестрына кертелүен оештыра.

5.29. Әгәр дә урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрү шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының булмый торуына бәйле рәвештә яисә юридик затның, шәхси эшкуарның фактта эшчәнлеге гамәлгә ашырылмавына бәйле рәвештә, яисә шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавына китергән бүтән гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында мөмкин булмаса, Дәүләт комитеның вазыйфаи заты, тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзелгән көннән башлап өч ай дәвамында мондый юридик затка,

шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык Планга кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТЛАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.30. «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен шушы Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

Административ процедура гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла:

– тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;
– тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;
– юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерүне үткәрү хакында хәбәр итү;
– тикшерүне үткәрү;
– тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар күрү.

5.31. Дәүләт комитеты бүлекләренең үз вәкаләтләре кысаларында тикшерүне үткәрүче башлыклары юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү өчен юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата документар тикшерүләр үткәрүгә вәкаләтле булган вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән башлап бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затларның исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

5.32. Шушы Регламентның 5.15 пунктында билгеләнгән тәртиптә юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) боерыгын әзерләү.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык.

5.33. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү үткәреләчәге турында теләсә нинди мөмкин булган ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон адресы буенча җибәрелгән электрон документ ярдәмендә хәбәр итә, әгәр дә мондый адрес, тиешенчә, бердәм дәүләт юридик затлар реестрында, бердәм дәүләт шәхси

эшкуарлар реестрында булса яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Дәүләт комитетына элегрәк тапшырылган булса.

Юридик затка, шәхси эшкуарга – үзеннән-үзе җайга салынучы оешма әгъзасына карата тикшерү үткәрелгән очракта җаваплы башкаручы шулай ук, планнан тыш документар тикшерүне үткәргәндә аннан вәкил катнашу яисә булу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үзеннән-үзе җайга салынучы оешмага хәбәр җибәрә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү.

5.34. Юридик зат, шәхси эшкуар, боерык күчермәсен алган мизгелдән башлап 10 эш көне эчендә, Дәүләт комитетына планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә бурычлы.

Күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм, тиешенчә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр дә Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Дәүләт комитетына тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

Дәүләт комитеты юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

5.35. Юридик затларның, шәхси эшкуарларның документларында бәян ителгән белешмәләрне бәяләү, тапшырылган документлардагы кисәтүләргә каршы юридик затларның, шәхси эшкуарларның аңлатмаларын карап тикшерү шушы Регламентның 5.18 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.36. Тикшерү нәтиҗәләрен формалаштыру, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү буенча чаралар кабул итү шушы Регламентның 5.19-5.21 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.37. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы шушы Регламентның 5.22 пункты нигезендә тиешле мәгълүматларның Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылуын һәм тиешле мәгълүматларның бердәм тикшерүләр реестрына кертелүен оештыра.

## «ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ШӘХСИ ЭШКУАРЛАРГА КАРАТА УРЫНГА ЧЫГЫП ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ» АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.38. Шушы Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән очраклар «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш

тикшерү үткәрү» административ процедурасын үткәрә башлау өчен нигез булып тора, шулай ук әгәр дә документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаса да:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы белдерүнамәдә һәм юридик затларның, шәхси эшкуарларның Дәүләт комитеты карамагында булган бүтән документларында бәян ителгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп белү;

2) юридик затлар, шәхси эшкуарлар эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасы шушы Регламентның 5.13 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.39. Еллык План нигезендә үз компетенцияләре кысаларында тикшерү үткәрүче Дәүләт комитеты бүлекләре башлыклары юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Әгәр дә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәргәндә экспертлар, экспертлык оешмалары катнашында контроль чараларын үткәрү таләп ителсә, Дәүләт комитеты рәисе (рәисенең урынбасары) аларга карата тикшерү үткәрелүче юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм тикшерелә торган затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, экспертлык оешмалары вәкилләрен җәлеп итә.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән башлап бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар (экспертлар, экспертлык оешмалары вәкилләре) исемлеге, җаваплы башкаручы.

5.40. Шушы Регламентның 5.15 пунктында билгеләнгән тәртиптә юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) боерыгын әзерләү.

Үтәү вакыты: урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык.

5.41. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында, шушы Регламентның 2.14 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган урынга чыгып планнан тыш тикшерүдән кала, теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр итә, әгәр дә мондый адрес тиешенчә бердәй дәүләт юридик затлар реестрында, бердәй дәүләт шәхси эшкуарлар

реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Дәүләт комитетына тапшырылган булса.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлаганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү.

5.42. Урынга чыгып планнан тикшерүне үткәрү шушы Регламентның 5.25 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.43. Тикшерү актын төзү, тикшерү актын юридик затка, шәхси эшкуарга тапшыру, тикшерү барышында ачыкланган бозу фактларына карата законнарда каралган чараларны күрү шушы Регламентның 5.19-5.21, 5.26 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.44. Җаваплы башкаручы юридик затларның, шәхси эшкуарларның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы белешмәләрне үз эченә алган язуны терки, шулай ук тикшерүне үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затның, шәхси эшкуарның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү турында теркәлгән язу.

5.45. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы шушы Регламентның 5.22 пункты нигезендә тиешле мәгълүматларның Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылуын һәм тиешле мәгълүматларның бердәм тикшерүләр реестрына кертелүен оештыра.

5.46. Әгәр дә шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының булмый торуы сәбәпле, яисә юридик затның, шәхси эшкуарның фактта эшчәнлеге гамәлгә ашырылмау сәбәпле, яисә шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китереп чыгарган башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты, аны үткәрүнең мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында актны төзегән көннән башлап өч ай дәвамында мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.

## 6. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕНЕҢ ҮТӘЛҮЕН ТИКШЕРЕП ТОРУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ РӘВЕШЛӘРЕ

6.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт вазыйфалары үтәлүен тикшереп тора, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт вазыйфалары тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Бу Регламент үтәлешен тикшереп тору Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.3. Шушы Регламент нигезендә дәүләт функциясен үтәү буенча гамәлләрнең вакытлары, эзлеклелеге саклануын, Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затлар тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп тора Дәүләт комитетының урынбасары һәм дәүләт функциясен үтәү алар вәкаләтенә керә торган Дәүләт комитетындагы бүлекләрнең башлыклары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.4. Дәүләт функциясен үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр Дәүләт комитетының агымдагы елга расланган эш планы нигезендә үткәрелә.

Планнан тыш тикшерүләр дәүләт функциясен үтәү барышында Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителгән яисә гамәлгә ашырылган карарларга яки гамәлләргә (гамәл кылмауларына) гражданнарның шикаятьләре нигезендә оештырыла һәм үткәрелә.

Тикшерүләр кызыксынган затларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә карарларына шикаятьләрне карап тикшерү, алар буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү максатларында үткәрелә.

Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затлар тарафыннан шушы Регламенттагы һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрнең үтәлүенә карата тикшерүләрне үткәрү ешлыгы Дәүләт комитетының агымдагы елга расланган эш планы нигезендә билгеләнә.

6.5. Әлеге Регламентның үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан тикшереп тору Дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләрне (гамәл кылмауны) һәм карарларны иң югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять кылу юлы белән гамәлгә ашырыла.

6.6. Тикшерүне үткәргәндә Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары, хокукка каршы килә торган гамәлләрне кылып (гамәл кылмыйча), хезмәт бурычларын тиешле дәрәҗәдә тиешле дәрәҗәдә үтәмәгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый

чаралар күрелгән көннән соң ун көн эчендә Дәүләт комитеты язмача рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итәргә бурычлы.

## 7. ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ, ШУЛАЙ УК АНДАГЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ КАРАРЛАРЫНА ҺӘМ ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАВЫН) СУДКА КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ДӘГЪВА БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар тикшерүне үткәргәндә Дәүләт комитетының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук андагы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм тикшерүне үткәргәндә алар кабул иткән карарларга судка кадәр (судтан тыш) дәгъва белдерергә хокуклы. Судка кадәр (судтан тыш) дәгъва белән мөрәҗәгать язмача рәвештә рәсмиләштерелергә һәм Дәүләт комитеты адресына җибәрелергә тиеш.

7.2. Дәүләт комитетының, андагы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва белдерү предметы булып Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның дәүләт функциясен үтәү барышында кабул иткән яисә гамәлгә ашырган карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмавы) тора.

7.3. Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъва Дәүләт комитеты рәисенә җибәрелергә мөмкин. Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты рәисенең гамәлләренә (гамәл кылмавына), карарларына дәгъва Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.4. Дәүләт комитетына мөрәҗәгать итүчедән шикаять килү Дәүләт комитетындагы вазыйфаи затларның карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу процедурасын башлау өчен нигез булып тора. Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту яисә карап тикшерүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

7.5. Әгәр дә язмача белдерелгән дәгъвада шикаятьне җибәргән гражданинның фамилиясе (юридик затның аталышы) яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон почта адресы) күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр дә күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Әгәр дә язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр дә аның фамилиясе (юридик затның аталышы) һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр дә мөрәҗәгать итүченең язмача дәгъвасынңа аның асылы буенча

элек җибәрелгән шикаятьләренә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән мәсьәлә бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты, күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең бер үк күзәтчелек органына яисә бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм шушы мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Әгәр дә шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлегенең булмавы турында хәбәр ителә.

Цензурасыз яисә мыскыллы җөмләләрне, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янауларны үз эченә алган язмача шикаять килгән очракта Дәүләт комитеты шикаятьне анда күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм шикаятьне җибәрүче мөрәҗәгать итүчегә хокук белән исәпләшмәүнең ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Суд карарына дәгъва белдерелгән шикаять, теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына дәгъва белдерү тәртибен аңлатып, аны җибәргән мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр дә шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне Дәүләт комитетына яңадан җибәрергә хокуклы.

7.6. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы. Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар Дәүләт комитеты адресына язмача рәвештә тиешле гарызнамә җибәрергә тиеш. Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары сорала торган белешмәләрне һәм документларны гарызнамә теркәлгән көннән соң 30 көн эчендә бирергә тиеш.

7.7. Судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьләр Дәүләт комитеты тарафыннан аларны теркәгән көннән соң 30 көн эчендә карала.

7.8. Судка кадәр (судтан тыш) дәгъва белдерү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

а) тикшерүне үткәргәндә вазыйфаи затның гамәленә (гамәл кылмавына) һәм аның тарафыннан кабул ителгән карарга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән дәгъваны канәгатьләндерү, ә атап әйткәндә:

– хезмәт тикшерүе барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәве фактлары ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә аларга карата чаралар күрү;

– хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик

затларга, шәхси эшкуарларга Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле затларга карата кабул ителгән чаралар турында мондый чаралар кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә язмача рәвештә хәбәр итү;

б) юридик затларга, шәхси эшкуарларга мондый карарны дәлилле рәвештә нигезләп, язмача рәвештә хәбәр итү юлы белән, дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру барышында гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылы торган) карарларга судка кадәрге (судтан тыш) дәгъваны канәгатьләндермичә калдыру.

Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турындагы дәлилләнгән җавап мөрәҗәгать итүчегә язмача рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә әлеге Административ регламентның 7.7 пунктында күрсәтелгән чор кысаларында җибәрелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына

1 нче кушымта

**Системалы рәвештә күзәтүне һәм анализлауны гамәлгә ашырганда гамәлләрнең эзлеклелеге буенча**
**БЛОК-СХЕМА**



Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешма-лары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына

2 нче кушымта

Раслыйм
Рәис урынбасары
___________________________
(ФИА, имза)
«___» ____________ 20__ел.

Системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау рәвешендә мәгълүмат ачу Стандартлары үтәлүен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлеге

| № | Тикшереп тору субъекты | ИНН | Тикшереп тору субъектының эшчәнлек өлкәсе | Тикшереп торуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затның ФИА |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |

Бүлек башлыгы: _____________________________________»_____» ___________ 20____ел.
(ФИА, имза)

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына

3 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

АЧЫКЛАНГАН БОЗУЛАРНЫ ТУКТАТУ (БЕТЕРҮ) ТУРЫНДА
мәгълүмат ачу стандартларын
№ _______ КҮРСӘТМӘ

Казан ш. «___»_______20___ел.

Мин, _________________, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе (рәисе в.б.),
(Ф.И.А.)
20___ елның «_____»______________№ ________ боерык нигезендә__________________________________
_____________________________________________________________________________карата
(шәхси эшкуарның Ф.И.А. яисә юридик затның аталышы)
үткәрелгән тикшерү материалларын карап тикшереп,

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ

______________________________________________________________________________________
(күрсәтмә бирелүче шәхси эшкуарның Ф.И.А. яки юридик затның аталышы)

| № п/п | Күрсәтмәнең эчтәлеге <*> | Үтәү вакыты | Күрсәтмәне чыгару нигезе <**> |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Күрсәтмәгә законда билгеләнгән тәртиптә дәгъва белдерелергә мөмкин. Дәгъва белдерү бу күрсәтмәне үтәүне туктата алмый.

Күрсәтмә бирелгән зат әлеге күрсәтмәнең үтәлүе турында Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына аны үтәү вакыты тәмамланган датадан соң ______ көннән дә соңга калмыйча мәгълүмат җибәрергә тиеш.

Рәис ______________________ __________________________________________________

(имза) (Ф.И.А.)

Күрсәтмә алынды

____________________________________ ______________________________________________________

(шәхси эшкуарның яки тикшерелүче юридик зат җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең) Ф.И.А.)

(шәхси эшкуарның имзасы яки тикшерелүче юридик затның җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең) Ф.И.А.)

--------------------------------

<*> Аңа карата тикшерү үткәрелгән зат тарафыннан башкарылырга тиешле төгәл чаралар күрсәтелә.

<**> Күрсәтмә итеп бирелә торган вазыйфаны күздә тотучы норматив хокукый актка сылтамалар күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына

4 нче кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

БЕРКЕТМӘ
административ хокук бозу турында № _________

«__» __________ 20__ ел.                    ___________________
(төзү урыны)

______________________________________________________________________
(беркетмәне төзегән затның вазыйфасы, Ф.И.А.)

______________________________________________________гамәлгә ашырылганда
(хокук бозуны ачыклау, турыдан-туры ачыклау, материаллар, хәбәрләр, гаризалар килү вакыйгалары турында житәрлек дәрәҗәдәге белешмәләр күрсәтелә)

______________________________________________________катнашында
(гражданинның, юридик затның вазыйфаи затының, законлы вәкиленең Ф.И.А.)

БИЛГЕЛӘДЕ:

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________.
(административ хокук бозуның урыны, кылынган вакыты һәм вакыйгасы турындагы мәгълүматлар, әлеге административ хокук өчен административ җаваплылык каралучы РФ КоАП статьясы күрсәтелә)

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, РФ КоАП 28.1-28.3статьялары нигезендә,
______________________________________административ хокук бозу турында беркетмә төзеде.
(беркетмә төзегән затның вазыйфасы, Ф.И.А.)

Аңа карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган зат турында мәгълүматлар:
______________________________________________________________________
(юридик зат: тулы аталышы, юридик адресы, ОГРН, ИНН; гражданин, вазыйфаи зат:Ф.И.А., туу датасы, паспорт белешмәләре, теркәлү урыны)

РФ КоАП 25.1 статьясының 1 өлеше нигезендә, аңа карата административ хокук бозу турында эш буенча эш башкару үткәрелә торган зат эшнең барлык материаллары белән танышырга, аңлатмалар бирергә, дәлилләр китерергә, үтенечнамәләр һәм кире кагулар белдерергә, яклаучының юридик ярдәменнән файдаланырга, шулай ук РФ КоАП нигезендә бүтән процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы.

Аңа карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган затның (аның вәкиленең) аңлатмасы:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________________________.

Хокуклар һәм бурычлар аңлатылды _____________ «__» _________ 20__ ел.
Беркетмә белән таныштым _____________ «__» _________ 20__ ел.
Беркетмә күчермәсен алдым _____________ «__» _________ 20__ ел.

_______________________________________________ _________________________________

(беркетмә төзүченең вазыйфасы, Ф.И.А.) (имза)

Имза куюдан яисә беркетмәне алудан баш тартканда бу хакта тамга куела
______________________________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына

5 кушымта

КАРАР

административ хокук бозу турындагы эш буенча

______________________________________________ «__» _________ 20__ ел.

(карап тикшерү урыны)

_______________________________________________________________________________________,

(карар чыгаручы затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

_______________________________________________________________________________катнашында

(гражданинның, вазыйфаи затның, юридик затның законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________________________карата

(гражданинның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның аталышы)

кузгатылган административ хокук бозу турында № ______ эш материалларын карап,

БИЛГЕЛӘДЕ:

_______________________________________________________________________________________

(административ хокук бозу турында эшне караганда билгеләнгән шартлар,

_______________________________________________________________________________________

Законнарның бозылган нормалары бәян итеЛә)

_______________________________________________________________________________________.

Бәян ителгәннәр нигезендә, РФ КоАП ________________________ статьяларына таянып,

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

_______________________________________________________________________________________

(гражданинның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның аталышы)

РФ КоАП _____ ст. _____ өлеше буенча административ җаваплылыкка тартырга һәм _____________ күләмендә административ штраф рәвешендә җәза билгеләргә.

_______________________________________ _______________________

(карар чыгарган вазтның вазыйфасы, Ф.И.А.) (имзасы)

Административ хокук бозу турындагы эш буенча әлеге карарга карар күчермәсе тапшырылган яки алынган көннән соң ун тәүлек эчендә дәгъва белдерелергә мөмкин (РФ КоАП 30.3 статьясының 1 өлеше).

РФ КоАП 31.1 статьясының 1 өлеше нигезендә административ хокук бозу турында эш буенча карар административ хокук бозу турында эш буенча карарга дәгъва белдерү өчен билгеләнгән чор узганнан соң үзенең законлы көченә керә, әгәр дә күрсәтелгән карарга дәгъва яисә ризасызлык белдерелмәсә. 30.1 статьясының 1 өлеше нигезендә вазыйфаи зат тарафыннан чыгарылган административ хокук бозу турында эш буенча карарга иң югары торучы органга, иң югары торучы вазыйфаи затка яисә эшне карап тикшерү урыны буенча район судына дәгъва белдерелергә мөмкин.

РФ КоАП 32.2 статьясының 1 өлеше нигезендә административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан административ штраф салыну турындагы карар үзенең законлы көченә кергән көннән соң яисә РФ КоАП 31.5 статьясында каралган кичектерү вакыты яисә бүлеп түләү вакыты тәмамланган көннән соң алтмыш көннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

Административ штраф суммасы түбәндәге реквизитлар буенча күчерелергә тиеш:
________________________________________________________________________________.

РФ КоАП 32.2 статьясының 5 өлеше нигезендә, РФ КоАП 32.2 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән чордан соң алтмыш көн узып киткәч административ штрафның түләнгән булуын таныклаучы документ булмаганда, карарны чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тиешле материалларны административ штраф суммасын федераль законнарда каралаган тәртиптә түләттерү өчен суд приставы-башкаручыга җибәрә. Моннан тыш, административ штрафны вакытында түләмәгән өчен гаепле зат түләнмәгән административ штраф суммасының икеләтелгән күләмендә административ штраф салынуны күздә тотучы РФ КоАП 20.25 статьясының 1 өлеше буенча административ җаваплылыкка тартыла.

Карар белән таныштым, күчермәсен алдым _____________________________________________________
_________________________________________________________________________________

«__» __________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына

6 нчы кушымта

КАРАР
административ хокук бозу турындагы эш буенча эш башкаруны туктату турында

_______________________________________ «__» _________ 20__ ел.
(карап тикшерү урыны)

___________________________________________________________________________,
(карар чыгаручы затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

__________________________________________________________________катнашында,
(гражданинның, вазыйфаи затның, юридик затның законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_____________________________________________________________________карата
(гражданинның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның аталышы)

кузгатылган административ хокук бозу турында № ______ эш материалларын карап,

БИЛГЕЛӘДЕ:

___________________________________________________________________________
(административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны юкка чыгара торган, билгеләнгән шартлар күрсәтелә)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________.

Бәян ителгәннәр нигезендә, РФ КоАП ________________________ статьяларына таянып,

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

________________________________________________________________бәйле рәвештә
(административ хокук бозу турында эш буенча эш башкаруны юкка чыгара торган шартлар күрсәтелә)

______________________________________________________________________карата
(гражданинның, вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затның аталышы)

административ хокук бозу турында кузгатылган № ____ эш буенча эш башкаруны туктатырга.

______________________________________________ ______________________
(карар чыгарган вазтның вазыйфасы, Ф.И.А.) (имзасы)

Административ хокук бозу турындагы эш буенча әлеге карарга карар күчермәсе тапшырылган яки алынган көннән соң ун тәүлек эчендә дәгъва белдерелергә мөмкин (РФ КоАП 30.3 статьясының 1 өлеше).

Карар белән таныштым, күчермәсен алдым ________________________________________________________


(юридик зат вәкиленең фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы, имзасы, дата)


«__» _________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының газ бүлү челтәрләре аша газ транспортлаштыручы табигый монополияләр субъектлары, электр энергиясен күмәртәләп һәм ваклап сату базарлары, җылы белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәрләре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының үтәлүе өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына

7 нче кушымта

**Планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашырганда гамәлләрнең эзлеклелеге буенча БЛОК-СХЕМА**




Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү, планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү
Документар тикшерү һәм (яисә) урынга чыгып тикшерү рәвешендә планлы яки планнан тыш тикшерү үткәрү
Мәгълүмат ачу стандартларын бозулар булмаганда
Тикшерү акты төзү
Мәгълүмат ачу стандартлары бозылуларны ачыклаганда
Тикшерү акты төзү
Хокук бозучы адресына мәгълүмат ачу стандартлары бозылуларны бетерү турында күрсәтмә бирү
РФ КоАП нигезендә административ хокук бозу турында эш кузгату
Күрсәтмә үтәлешен тикшереп тору, бозуларның бетерелүен мониторинглау
РФ КоАП нигезендә административ эш башкару